КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1745

Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген индикатив бәяләү турында

Татарстан Республикасының тулы вәкаләтле, даими, сәүдә-икътисадый вәкиллекләре эшчәнлеген индикатив бәяләүне гамәлгә кертү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 елга һәм 2025 елның план чорына Татарстан Республикасының тулы вәкаләтле, даими, сәүдә-икътисадый вәкиллекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларын;

2024 елга республика башкарма хакимият органнары белән Татарстан Республикасы тулы вәкаләтле, даими, сәүдә-икътисадый вәкиллекләренең үзара хезмәттәшлеге күрсәткечләрен;

республика башкарма хакимият органнары тарафыннан Татарстан Республикасының вәкаләтле, даими, сәүдә-икътисадый вәкиллекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары (алга таба шул ук эзлеклелектә – Татарстан Республикасы вәкиллекләре, индикаторлар) үтәлешен мониторинглау тәртибен.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

индикаторларны үтәү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, индикаторларның иң яхшы күрсәткечләренә ирешүен бүләкләү өчен Татарстан Республикасы вәкиллекләрен стимуллау турында карар кабул итәргә хокуклы;

еллык индикаторларның факттагы күрсәткечләре хисап чорыннан соң килә торган II квартал мәгълүматларын бәяләгәндә исәпкә алына;

хисап чорына мәгълүмат булмаган квартал индикаторларының факттагы күрсәткечләре киләсе кварталда мәгълүматларны бәяләгәндә исәпкә алына.

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына (алга таба – Министрлык):

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 16нчы көненә кадәр, һәм 30 декабрьгә кадәр IV квартал индикаторлары буенча республика башкарма хакимият органнары тарафыннан квартал күрсәткечләренең үтәлешен мониторинглау мәгълүматлары нигезендә Татарстан Республикасы вәкиллекләренең аларга ирешү йомгаклары турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәгълүмат кертергә;

2024 елның 20 мартына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында алга таба карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы вәкиллекләренең узган елга индикаторларның иң чик күрсәткечләренә ирешү йомгаклары турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәгълүмат кертергә;

кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары белән берлектә, 2024 елның 25 декабренә кадәр 2025 елга һәм 2026 елның план чорына Татарстан Республикасы вәкиллекләре өчен индикаторларның чик күрсәткечләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

4. Республика башкарма хакимият органнарына:

хисап кварталыннан соң килә торган айның 10сына кадәр һәм 20 гыйнварга кадәр IV квартал индикаторлары буенча Министрлыкка һәр квартал күрсәткечләренең үтәлешен мониторинглау мәгълүматлары нигезендә Татарстан Республикасы вәкиллекләренең аларга ирешү йомгаклары турында мәгълүмат кертергә;

2024 елның 1 ноябренә кадәр 2025 елга һәм 2026 елның план чорына индикатив бәя формалаштыру максатларында Министрлык тарафыннан расланган форма буенча республика башкарма хакимият органнарына беркетелгән индикаторларга төзәтмә кертү турында Министрлыкка тәкъдимнәр җибәрергә.

5. Индикаторларның үтәлешен исәпләп чыгару (% үтәл) Министрлык тарафыннан түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$\% \text{ үтәл} = \frac{A}{N} + 100,$$

монда:

A – җаваплы республика башкарма хакимият органнарын бәяләү буенча үтәлгән индикаторлар саны;

N – индикаторларның гомуми саны.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2020 елның 25 апрелендәге 329 номерлы;

«Татарстан Республикасы вәкиллекләре эшчәнлеген индикатив бәяләү турында» 2023 елның 25 гыйнварындагы 41 номерлы.

7. Бу карар (әлеге карарның 2024 елның 1 августыннан үз көченә керә торган 6 пунктындагы өченче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин